КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 ноябрь г.Казань № 920

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 май, 356 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 408 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу, рәсми рәвештә бастырып чыгару, аларның үз көченә керүе, Татарстан Республикасында Россия Федерациясе хокукый мәйданы бердәмлеген тәэмин итүнең аерым мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларын үз көчен югалткан дип тану турында» 2017 ел, 28 сентябрь, ПУ-861 нче Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрендә:

2.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, шул исәптән дәүләт серендәге мәгълүматлары яки конфиденциаль характердагы мәгълүматлары булган актлар дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.»;

2.4 нче пунктта:

өченче абзацта «3» санын «2» санына алыштырырга;

алтынчы абзацта «бастырып чыгару (кабул итү) турында» дигән сүзләрне «бастырып чыгару (кабул итү)» дигән сүзләргә алыштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хокукый мөнәсәбәтләрнең тиешле өлкәсен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында белешмәләр һәм бастырып чыгарылган (кабул ителгән) норматив хокукый актка туры китерү вакытлары турында мәгълүмат;»;

2.6 нчы пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«норматив хокукый актка хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрүне;»;

2.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Әгәр дә хокукый экспертиза үткәргәндә бу актның законнарга туры килмәве билгеләнсә, шулай ук коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә бу актта коррупция гамәлләрен кылуга китерә торган факторлар ачыкланганда, норматив хокукый актны теркәүгә алудан баш тартыла.»;

2.10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Бу Кагыйдәләр белән билгеләнгән норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә бирү тәртибе үтәлмәгән очракта, шулай ук республика башкарма хакимият органы мөрәҗәгате нигезендә, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алмыйча кире кайтара.»;

3.2.2 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рәсми бастырып чыгарылырга тиешле норматив хокукый актлар дәүләт теркәвенә алу турындагы билге белән норматив хокукый акт бастырып чыгарган (кабул иткән) республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына электрон рәвештә pdf форматында, шулай ук рус телендә doc яки docx форматында кертелә.»;

өченче абзацта «күчермәләрен» сүзен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 ел, 6 апрель, ТРЗ-64 нче Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2005 ел, 28 апрель,

ПУ-147 нче Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 нче пунктта:

беренче абзацта «3 333,2» саннарын «3 486,655» саннарына алыштырырга;

икенче абзацта «579,5» саннарын «607,952» саннарына алыштырырга;

өченче абзацта «2 753,7» саннарын «2 878,703» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 нче пунктта «закон проектлары һәм хокукый тәэмин итүне һәм» сүзләрен, «Татарстан Республикасының бердәм норматив хокукый актлар банкын булдыру һәм алып бару,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлегенең шәхес һәм дәүләт хокукларын һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен тиешенчә яклауны тәэмин итә торган дәрәҗәсенә ирешү.»;

4.1.17 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга:

4.1.29 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.29. Юридик затларга үз исемнәрендә Татарстан Республикасы рәсми исемнәрен куллануга рөхсәтнамәләр бирә.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 821 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

24 нче пунктта «закон проектлары һәм башка», «һәм хокукый тәэмин итү», «Татарстан Республикасы норматив хокук актларының бердәм банкын формалаштыру һәм алып бару;» сүзләрен төшереп калдырырга, «юридик затлар исемнәрендә «Татарстан Республикасы», «Татарстан» дигән исемнәрдән һәм алар нигезендә ясалган сүзләрдән һәм сүзтезмәләрдән файдалануны тәртипкә салу» дигән сүзләрне «юридик затлар исемнәрендә Татарстан Республикасы рәсми исемнәрен куллануны тәртипкә салу» дигән сүзләргә алыштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2013 ел, 13 сентябрь, 656 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 28 май, 361 нче; 2014 ел, 26 июнь, 440 нчы; 2015 ел, 11 май, 334 нче; 2015 ел, 11 ноябрь, 843 нче; 2016 ел, 17 май, 319 нчы; 2016 ел, 6 август, 535 нче; 2016 ел, 14 декабрь, 931 нче; 2017 ел, 23 июнь, 422 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең алтынчы абзацында «һәм хокукый тәэмин итү» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

V бүлекнең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлегенең шәхес һәм дәүләт хокукларын һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен тиешенчә яклауны тәэмин итә торган дәрәҗәсенә ирешү.»;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа паспортының «Программаның бурычлары» юлындагы 1 нче пунктта түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлегенең шәхес һәм дәүләт хокукларын һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен тиешенчә яклауны тәэмин итә торган дәрәҗәсенә ирешү.»;

I бүлекнең өченче абзацында «һәм хокукый тәэмин итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

II бүлегендә:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлегенең шәхес һәм дәүләт хокукларын һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен тиешенчә яклауны тәэмин итә торган дәрәҗәсенә ирешү.»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Юридик затлар исемнәрендә Татарстан Республикасы рәсми исемнәрен куллануны тәртипкә салу.»;

унберенче абзацта «закон проектлары һәм башка», «һәм хокукый тәэмин итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

V бүлекнең өченче абзацында «закон проектлары һәм башка», «һәм хокукый тәэмин итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

Ярдәмче программага теркәлгән кушымтада:

«1 нче бурыч. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының закон проектлары һәм башка норматив документлар эшләү эшчәнлеген хокукый тәэмин итүнең шәхес һәм дәүләт хокукларын һәм аларның

законлы мәнфәгатьләрен тиешенчә яклауны тәэмин итә торган дәрәҗәсенә ирешү» юлында «закон проектлары һәм башка», «хокукый тәэмин итүнең» сүзләрен төшереп калдырырга, «эшчәнлеген» сүзен «эшчәнлегенең» сүзенә алыштырырга;

1.1 нче пунктта «закон проектлары һәм башка», «һәм хокукый тәэмин итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. «Юридик затларга үз исемнәрендә «Татарстан Республикасы», «Татарстан» дигән исемнәрдән, шулай ук алар нигезендә ясалган сүзләрдән һәм сүзтезмәләрдән куллануга рөхсәтнамәләр бирү.».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкның яшәү сыйфатын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары мониторингы өчен мәгълүматлар составын һәм аларны бирүнең кабатлануын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында» 2016 ел, 19 октябрь, 758 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 июнь, 454 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Халыкның яшәү сыйфатын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары мониторингы өчен мәгълүматлар составына һәм аларны бирүнең кабатлануына, «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **XVI. Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы** | | | | |
| | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлеген яраштыру (02.04.01) | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына кертелгән һәм хокукый экспертиза үткән хокук актлары проектларының гомуми санында хокукый характердагы (федераль, республика законнарына каршы килә торган) искәрмәләр белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан эшләп бетерү өчен кире кайтарылган хокук актлары проектлары өлеше, процент | квартал | V = A/B x 100, монда: A – Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында хокукый экспертиза үткән хокук актлары проектларының гомуми санында хокукый характердагы (федераль, республика законнарына каршы килә торган) искәрмәләр белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан эшләп | квартал | Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | бетерү өчен кире кайтарылган хокук актлары проектлары өлеше, берәмлек;<br>В – Татарстан Республикасының Юстиция министр-лыгында хокукый экспертиза үткән хокук актлары проектларының гомуми саны, берәмлек | | |
| | Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03) | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының теркәлгән, суд тарафыннан законнарга туры килми һәм алар закон көченә керү көненнән бер ел эчендә гамәлдә булмый дип танылган норматив хокук актлары саны, берәмлек | квартал | ведомство мәгълүматлары | квартал | Татарстан Республика-сының Юстиция министрлы-гы». |

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2017 ел, 16 март, 147 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 7 июнь, 352 нче; 2017 ел, 17 октябрь, 793 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә, «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы | | | | | | | | | |
| | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлеген яраштыру (02.04.01) | | | | | | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына кертелгән һәм хокукый экспертиза үткән хокук | квартал | Х | <=5 | <=4 | <=4 | <=4 | <=4 | <=3 | <=3 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | актлары проектларының гомуми санында хокукый характердагы (федераль, республика законнарына каршы килә торган) искәрмәләр белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан эшләп бетерү өчен кире кайтарылган хокукый актлар проектлары өлеше, процент | | | | | | | | | |
| | Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03) | | | | | | | | | |
| 2. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының теркәлгән, суд тарафыннан законнарга туры килми һәм алар законнар нигезендә үз көченә кергән көннән бер ел эчендә гамәлдә булмый дип танылган норматив хокук актлары саны, берәмлек | квартал | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | Гомуми индикаторлар | | | | | | | | | |
| 3. | Дәүләт заказчысы-яраштыручысы тарафыннан дәүләт программалары үтәлеше, процент | еллык | Х | Х | Х | Х | Х | 100 | 100 | 100 |
| 4. | Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын канәгатьләндерү дәрәҗәсе, процент | еллык | Х | 80 | Х | Х | Х | 85 | 90 | 90 |
| 5. | Түбәндә санап үтелгән затлар тарафыннан үтәү вакыты билгеләнгән йөкләмәләрнең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларының билгеләнгән | квартал | Х | Х | 100 | 100 | 100 | 100 | Х | Х |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тикшерүдә тоту вакытларында үтәлгән йөкләмәләре өлеше, процент | | | | | | | | | |
| 6. | Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында, боерыкларында бирелгән шәхси йөкләмәләрнең гомуми санында әлеге Татарстан Республикасының норматив хокук актларында бирелгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан үтәлгән шәхси йөкләмәләр өлеше, шул исәптән «Ачык Татарстан» системасында хисапларны регламент нигезендә бастырып чыгаруның гомуми санында үз вакытында яңартылган хисаплар өлеше, процент | квартал | X | X | 100 | 100 | 100 | 100 | X | X |
| 7. | Түбәндә санап үтелгән затлар тарафыннан үтәү вакыты билгеләнгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча йөкләмәләрнең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан билгеләнгән тикшерү вакытларында үтәлгән Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү буенча йөкләмәләре өлеше, процент | квартал | X | X | 100 | 100 | 100 | 100 | X | X |
| 8. | Татарстан Республикасы | квартал | X | X | 100 | 100 | 100 | 100 | X | X |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Министрлар Кабинетының регламент вакытларында килештерелгән карарлары һәм боерыклары проектлары өлеше, процент | | | | | | | | | |
| 9. | Төзелгән килешүләрнең гомуми кыйммәтендә сатып алуларның барып чыкмаган көндәшкә сәләтле ысуллары нәтиҗәләре буенча төзелгән килешүләр кыйммәте өлеше, процент | еллык | 3,3 | 7 | X | X | X | 7,0 | 7,0 | 7,0 |
| 10. | Сатып алуларның җыелма еллык күләменнән коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларда һәм кече эшмәкәрлек субъектларында урнаштырылган сатып алулар өлеше, процент | еллык | X | X | X | X | X | >=15 | X | X |
| 11. | Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен билгеләнгән регламент вакытларында тормышка ашыру максатларында кертелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокук актлары проектларының әлеге норматив хокук актлары гомуми күләмендәге өлеше, процент | квартал | X | X | 100 | 100 | 100 | 100 | X | X». |

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасының норматив хокук актларының бердәй банкын формалаштыру һәм алып бару өчен норматив хокук актларын кертү тәртибен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 427 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокук актларының бердәй банкын формалаштыру һәм алып бару өчен норматив хокук актларын кертү тәртибен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 427 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 ел, 17 гыйнвар, 8 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Норматив хокукый актлары бердәм банкын булдыру һәм алып бару өчен норматив хокукый актларны тапшыру тәртибе турында» 2002 ел, 18 июль, 427 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Норматив хокукый актлары бердәм банкын булдыру һәм алып бару өчен норматив хокукый актларны тапшыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 27 апрель, 291 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин